# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 2** **14 ноябрь 2025 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Туйкә авылында 2026 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары,» Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Туйкә авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026елда Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пункты территориясендә 1,2 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлар уку формасына; махсус хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаилә әгъзаларына, - Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарга тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 (Ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, чапкыч сатып алу, үлән чабу, чүп җыю, агач һәм куакларны кисү);
- ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (үлән чабу, чүп-чар җыю, зиратта агач һәм куакларны кисү, гербицид сатып алу, тоташ гербицид белән химик эшкәртү ) ;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Гагарин, Яшьләр урамнары буенча вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу, Яшьләр урамындагы юлны профильләштерү);

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;
ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.